**МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.07.2019 г. Казань № под-1074/19

Уналты яшенә җитмәгән затка (затларга) өйләнешүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының норматив-хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Уналты яшенә җитмәгән затка (затларга) өйләнешүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 16 яшенә җитмәгән затка (затларга) өйләнешүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 13 июнендәге 3598/12 номерлы, «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2012 елның 13 июнендәге 3598/12 номерлы боерыгы белән расланган «Уналты яше тулмаган затка (затларга) өйләнешүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 22 июнендәге 1245/16 номерлы, «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2012 елның 13 июнендәге 3598/12 номерлы боерыгы белән расланган «Уналты яшенә җитмәгән затка (затларга) өйләнешүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 12 маендагы 2689/14 номерлы боерыкларын, «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының аерым боерыкларына

үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 4 сентябрендәге 9242/15 номерлы боерыгының 1 пунктын гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары А.М.Әсәдуллинага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр Р.Т.Борһанов

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2019 елның 30.07.2019 № под-1074/19 боерыгы белән расланды

**Уналты яшенә җитмәгән затка (затларга) өйләнешүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент уналты яшенә җитмәгән затка (затларга) өйләнешүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Хезмәттән файдаланучылар: ундүрт яшьтән алып уналты яшькә кадәрге, яшәгән урыны Татарстан Республикасында булган зат(лар) (алга таба – уналты яшенә җитмәгән зат(лар)).

Гариза бирүчеләр: уналты яшенә җитмәгән зат (затлар, аның ата-анасы яки аларны алмаштыра торган затлар (уллыкка алучылар, попечительләр);

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлыкның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Дзержинский урамы, 3, 205 нче, 207 нче каб.

Министрлыкның эш графигы: көн саен, шимбә, якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9:00 башлап 18:00 кадәр, җомга 9:00 башлап 17:00 кадәр, төшке аш: 12:30 башлап 13:30 кадәр.

Җәмәгать транспортында «Ирек мәйданы», «КАИ», «Үзәк стадион» тукталышына кадәр килергә кирәк.

Керү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

1.3.2. Белешмә телефоннары: 293-62-15, 292-49-04.

1.3.3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайты адресы: http://www.mon.tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша.

Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4., 2.5, 2.8,

2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала.

2) «Интернет» челтәре аша:

Татарстан Республикасының рәсми сайтында (http://www.mon.tatar.ru);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә телефон аша);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләренә бәйле мәгълүмат Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтына (http://www.mon.tatar.ru) автоматлаштырылган идарә системалары һәм мәгълүмат куркынычсызлыгы бүлеге белгече тарафыннан урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Гаилә кодексы (алга таба – РФ Гаилә кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1996, №1, 16 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Гражданлык хәле актлары турында» 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 143-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1997, №47, 5340 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 48-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, №17, 1755 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Гаилә кодексы (алга таба – ТР Гаилә кодексы) (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2009, №1, 4 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 2004, №21, 2021 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2008, №3, 212 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 елның 8 маендагы 287 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы турында нигезләмә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 2009, № 19-20, 0798 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 287 номерлы нигезләмә);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

1.5. Бу регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

**техник хата** – Министрлык тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләрне кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу хатасы, басма хата, грамматик яки арифметик хата);

**дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны** – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мрәҗәгать аңлашыла («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 1 п.). Гаризаның формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелде.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең | Уналты яше тулмаган затка | ТР Гаилә кодексының 10 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| аталышы | (затларга) өйләнешүгә рөхсәт бирү | |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтә торган башкарма хакимият органының аталышы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | ТР Гаилә кодексының 10 ст. |
| 2.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Уналты яше тулмаган затка (затларга) өйләнешүгә рөхсәт бирү турында ТР мәгариф һәм фән министры боерыгы.<br>Уналты яше тулмаган затка (затларга) өйләнешүгә рөхсәт бирүдән баш тарту турында боерык | ТР Гаилә кодексының 10 ст.<br>ТР Гаилә кодексының 13 ст. |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге булган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору вакыты | 13 эш көне дәвамында<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү чорын туктатып тору каралмаган | ТР Гаилә кодексының 10 ст. 6 өлеше |
| 2.5. Дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки бүтән норматив хокукый актлар нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле кирәкле документларның тулы исемлеге, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе | 1) өйләнешүгә рөхсәт турында гаризалар (1 нче һәм 2 нче кушымталар) Министрлыкка язмача рәвештә уналты яше тулмаган зат (затлар), аның ата-анасы яки аларны алмаштыра торган затлар (уллыкка (кызлыкка) алган затлар, попечительләр) тарафыннан бирелә;<br>ата-ананың берсе ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән, суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган, уналты яше тулмаган затны тәрбияләү һәм карап тотудан баш тарткан, шулай ук аның урнашу урыны билгеләнмәгән очракта, гариза ата-ананың берсеннән генә кабул ителергә мөмкин;<br>3) ата-аналар (аларны алыштыра торган затлар) һәм гаилә корырга теләгән зат (затлар) арасында каршылыклар булган очракта, уналты яше тулмаган затның (затларның) өйләнешүгә рөхсәт турында гаризасы яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органы ризалыгы белән карала.<br>4) өйләнешүгә рөхсәт турында гариза белән бергә түбәндәге документлар | ТР Гаилә кодексының 10 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | тапшырыла:<br>өйләнешергә теләгән затларның шәхесен таныклый торган документлар;<br>уналты яше тулмаган затның (затларның) ата-анасың (аларны алыштыра торган затларның) шәхесен таныклый торган документлар;<br>дәүләт сәламәтлек саклау системасының яисә муниципаль сәламәтлек саклау системасының медицина оешмасыннан йөклелек турында белешмә, йә өйләнешергә теләгән затларның уртак баласы (балалары) туу турында таныклык, һәм аталыкны билгеләү турында таныклык, йә өйләнешергә теләгән затларның берсенең тормышына турыдан-туры куркыныч янавын раслый торган документлар.<br>Документларның күчермәләре төп нөсхәләре булганда берәр нөсхәдә бирелә.<br>Почта аша җибәргәндә, гаризага әлеге пунктта күрсәтелгән, законда билгеләнгән тәртиптә расланган документларның күчермәләре теркәлә.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче шәхси мөрәҗәгать иткәндә Министрлыкта алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче зат тарафыннан);<br>тапшырылуы турында белдерү кәгазе килә торган заказлы почта юлламасы белән.<br>Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган | |

| | | |
|---|---|---|
| | электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша да, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>1) уналты яше тулмаган затның (затларның) тууын дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр;<br>2) ата-ана (аларны алмаштыра торган затлар) һәм әлеге зат (затлар) арасында каршылыклар булганда, уналты яше тулмаган затның (затларның) өйләнешүенә ризалык турында яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органы бәяләмәсе.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Югарыда санап үтелгән, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагында булган документларны гариза бирүчедән таләп итү тыела. | ТР Гаилә кодексының 10 ст. |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча, норматив хокукый актларда каралган очракларда, алар белән килештерү таләп ителә торган һәм бу гамәл дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве.<br>2. Тапшырылучы документларда алдан килешенмәгән төзәтүләрнең | ТР Гаилә кодексының 10 ст. 5 өлеше, 4 п.<br>ТР Гаилә кодексының 10 ст. 8 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| | булуы. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яки күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүдән кире кагыла:<br>1. ТР Гаилә кодексының 10 ст. 4 өлешендә билгеләнгән махсус шартлар булмаганда: йөклелек, өйләнешергә теләгән гражданнарның уртак баласы (балалары) туу, бер якның тормышына турыдан-туры куркыныч янавы.<br>2. Татарстан Республикасы территориясендә теркәлмәү.<br>3. Документларның түбәндәгеләр тарафыннан тапшырылуы:<br>1) инде теркәлгән гаиләдә яшәгән затларның берәрсе тарафыннан;<br>2) якын туганнар (түбән һәм югары линия буенча (ата-аналар һәм балалар, бабай, әби һәм оныклар), тулы һәм тулы булмаган (уртак әтисе яки әнисе булган) абыйлары (энеләре) һәм апалары (сеңелләре) тарафыннан;<br>3) уллыкка (кызлыкка) алган һәм уллыкка (кызлыкка) алынган затлар тарафыннан;<br>4) берсе булса да психик авырулар нәтиҗәсендә суд тарафыннан эшкә сәләтсез дип танылган затлар тарафыннан.<br>4. 2.5 пунктның 4 пунктчасына ярашлы тапшырылган документлар закон белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәгәндә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктату өчен нигезләр юк | ТР Гаилә кодексының 10 ст. 5 өлеше, 4 п.<br>ТР Гаилә кодексының 10 ст. 8 өлеше<br>ТР Гаилә кодексының 11 ст. |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын яки башка төр түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм аны алу нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә кирәкле һәм зарури хезмәтләр өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләүнең күләмен хисаплау методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артык булырга тиеш түгел.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризасын, шул исәптән электрон рәвештә, теркәү вакыты | Гариза кергән көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәлә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә аталган объектларның үтемлелеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларны урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү тиешле күрсәткечләр белән җиһазландырылган биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдаланучыларны кабул итү әлеге максатлар өчен махсус бүлеп бирелгән, түбәндәгечә җиһазландырылган урыннарда башкарыла:<br>янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле булган мебель;<br>мәгълүмат стендлары.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу мөмкинлеге тудырыла, шул исәптән бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән бәйләнешкә | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләр:<br>бинаның җәмәгатьчелек транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның | |

| | | |
|---|---|---|
| керүләренең саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрен ең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турындагы мәгълүматны, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологиләреннән файдаланып, алу мөмкинлеге | тиешле санда булуы;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында тулы мәгълүмат булуы;<br>биналарда инвалидлар өчен файдалана алырлык булуның законда каралган шартлары.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән сыйфатлана:<br>документларны кабул иткәндә һәм мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен тапшырганда чиратларның;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын бозуларның;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтә торган дәүләт граждан хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләрнең;<br>дәүләт хезмәтен күрсәткән дәүләт граждан хезмәткәрләренең мөрәҗәгать итүчеләргә карата дорфа, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләрнең.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган документларны тапшырганда Министрлык белгече белән мөрәҗәгать итүченең үзара бәйләнешкә керүләренең саны, турыдан-туры бер мәртәбә бәйләнешкә кергәндә – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны җибәргәндә, почта аша – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмаганда), ә мөрәҗәгать итүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган барлык кирәкле документларны тапшырган очракта, үзара хезмәттәшлек итү зарурлыгы юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Мөрәҗәгать итүче белән үзара хезмәттәшлек итүнең вакыт озынлыгы – 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза | |

| | | |
|---|---|---|
| | бирүне дә кертеп, күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүматны мөрәҗәгать итүче mon.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгеннән алырга мөмкин | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Гариза һәм документларның күчермәләре электрон формада Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша түбәндәге адрес буенча җибәрелергә мөмкин: http://uslugi.tatar.ru/, аннан соң рөхсәт алганда документларның төп нөсхәләрен күрсәтү зарур. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Уналты яшенә җитмәгән затка (затларга) өйләнешүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедуралардан тора:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) документларны кабул итү һәм гаризаны теркәү;

3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү;

4) уналты яше тулмаган затка (затларга) өйләнешүгә рөхсәт бирү турында боерык проектын яисә өйләнешүгә рөхсәт бирүдән баш тарту турында боерык проектын әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге турында блок-схема әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасында күрсәтелде.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү

Мөрәҗәгать итүче шәхсән үзе, телефон, электрон почта аша (http://www.mon.tatar.ru) һәм (яки) хат белән дәүләт хезмәтеннән файдалану

тәртибе турында консультация алу өчен Министрлыкка мөрәҗәгать итә, белгеч гариза бланкын бирә һәм бланкны тутырганда, зарурлык булганда, ярдәм күрсәтә.

Министрлык хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документлар исемлегенең составы, формасы һәм эчтәлеге буенча, консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү, техник хаталарны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтүдә гариза бирүчегә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бирелгән документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләү, кисәтүләр белдерү, шул исәптән дәүләт хезмәтен алу өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү өлешендә гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү.

3.3. Документларны кабул итү һәм гаризаны теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән үзе, законлы вәкилләр озатуында йә почта аша әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар белән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлегенә (алга таба – Бүлек) гариза бирә.

3.3.2. Гражданнарны кабул итүче Бүлек белгече Әлеге регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерә.

Әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаганда, белгеч гаризаны һәм аңа теркәп бирелә торган документларны терки.

Әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итеп алудан баш тарту нигезләре булган очракта, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәүдән баш тарту өчен каршылыклар булуы хакында шәхсән хәбәр итә һәм аңа, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны кайтарып бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүчене кабул иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул итеп алынган документлар, гаризаларны теркәү журналында теркәү язуы яки мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелгән документлар.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү

3.4.1. Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша түбәндәге мәгълүматларны сорап, рәсми мөрәҗәгать җибәрә:

уналты яше тулмаган затның (затларның) тууын дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләрне;

ата-ана (аларны алмаштыра торган затлар) һәм, әлеге зат (затлар) арасында каршылыклар булганда, уналты яше тулмаган затның (затларның) өйләнешүенә ризалык турында яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органы бәяләмәсен.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар узган процедураны тәмамлаганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: уналты яше тулмаган затның (затларның) тууын дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләрне, уналты яше тулмаган затның (затларның) өйләнешүенә ризалык турында яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органы бәяләмәсен сорап җибәрәлгән рәсми мөрәҗәгать.

3.4.2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә, мәгълүмат белән тәэмин итүче белгеч, соратып алына торган документларны (мәгълүматларны) җибәрә яки Министрлыкка мәгълүмат бирүдән баш тарту турында хәбәр бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләр килгән вакыттан башлап 5 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән документлар (белешмәләр) яисә баш тарту турында хәбәр.

3.5. Боерык проектын әзерләү

3.5.1. Бүлек белгече кабул ителгән документлар һәм мәгъүматлар нигезендә документларны әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булуын (булмавын) тикшерә.

Рөхсәт бирүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигез булмаса, белгеч өйләнешүгә рөхсәт турында боерык проектын әзерли.

Өйләнешүгә рөхсәт бирүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигез булган очракта, бүлек белгече өйләнешүгә рөхсәт бирүдән баш тарту турында боерык проектын әзерли.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар узган процедураны тәмамлаганнан соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында боерык проекты.

3.5.2. Бүлек башлыгы рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында боерык проектын килештерә һәм министрга кул кую өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар узган процедураны тәмамлаганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министрга юлланган рөхсәт бирү турында яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында боерык проекты.

3.5.3. Министр рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы боерыкны имзалый һәм Бүлек белгеченә кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар узган процедураны тәмамлаганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында кул куелган боерык.

3.6. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.6.1. Бүлек белгече рөхсәт яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында кул куелган боерыкны алып, аны терки һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар узган процедураны

тәмамлаганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте нәтиҗәсе турында мөрәҗәгать итүчегә белдерү.

3.6.2. Бүлек белгече гариза бирүчедән журналга имза куйдырып дәүләт хезмәте нәтиҗәсен үз кулына бирә (яки кулга тапшыру турында белдерү хаты белән заказлы хат итеп, почта аша җибәрә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән дәүләт хезмәте нәтиҗәсе.

3.7. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк (алга таба – күпфункцияле үзәк), күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү.

3.7.1. Күпфункцияле үзәкләрдә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

3.8. Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта техник хаталар ачыкланган очракта, гариза бирүче Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасына ярашлы форма буенча техник хаталарны төзәтү турында гариза;

гариза бирүчегә техник хатасы булган, дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак бирелгән документ;

юридик көчкә ия, техник хатасы булуын таныклый торган документлар.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән йә почта яисә электрон почта аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша тапшырыла.

3.8.2. Бүлек белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм теркәлгән документлар белән гаризаны терки.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.8.3. Бүлек белгече төзәтүләр кертү максатында хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны карый һәм әлеге Регламентның 3.5.1-3.5.3 пунктларында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы булган документның төп нөсхәсен алып, кул куйдыртып, төзәтелгән документны шәхсән гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) тапшыра яки аның адресына почта аша (электрон почта аша), техник хатасы булган документның төп нөсхәсен Министрлыкка тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен

бирү (җибәрү).

**Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре**

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклаудан һәм бетерүдән, дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә тикшерүләр уздырудан, карарлар кабул итүдән һәм учреждение вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына шикаятьләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап әзерләүдән тора.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре булып түбәндәгеләр тора:

- дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча документларның проектларына хокукый экспертиза уздыру. Экспертизалар нәтиҗәсе булып проектларга имза салу тора;

- эш алып барылышына карата билгеләнгән тәртиптә уздырыла торган тикшерүләр;

- дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр уздыру.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырылганда дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә һәм карарлар кабул ителгәндә гамәлләр кылуны тикшереп тору максатларында министрга дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы булган белгеч, эш башкару хезмәте белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге Министрлыкның структур бүлекчәләре турында нигезләмәләрдә һәм вазыйфаи регламентларда билгеләнә.

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, гаепле затлар закон нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгатьләрен вакытында карамаган өчен җаваплы була.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органнар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә

**(гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе**

5.1. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар Министрлыкка яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

- гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасын теркәү срогы бозылганда;

- дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

- мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыруны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

- дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларда баш тарту нигезләре каралмаган булса;

- дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

- дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

- дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

- дәүләт хезмәте яисә муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

- дәүләт хезмәте яисә муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.2. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты

(http://www.mon.tatar.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылуга шикаять белдерелгән очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының йә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының йә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.5. Шикаятькә мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәп бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять дәүләт хезмәтеннән файдалану буенча гариза тапшыручы зат тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Министрлык түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирү рәвешендә шулай ук бүтән төрле рәвештә;

2) шикаять канәгатьләндерелмичә кире кагыла.

Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача һәм, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүне гамәлгә ашыручы орган, күпфункцияле үзәк яисә оешмада гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

**Уналты яшенә җитмәгән затка (затларга) өйләнешүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта**

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрына ________________________________
(инициаллар, фамилия)

кемнән____________________________________
(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме)

Яшәү урыны ______________________________
_____________________________________________
Тел. _______________________________________
(кесә, өй)

## Гариза

2009 елның 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 10 статьясындагы 3-4 пункты нигезендә Сездән,

______________________________________________________________бәйле рәвештә
(сәбәбен күрсәтергә)

миңа __________________________________________________________________
(фамилия, исем, ата исеме, туу датасы)

_________________________________________________________ белән өйләнешүгә
(фамилия, исем, ата исеме, туу датасы)

ризалык бирүегез турында үтенәм.

______________________________________________________________________________

Гаризага терким:

__________________ ___________________ ____________________________________
(дата) (имза) (тулы имза)

**Уналты яшенә җитмәгән затка (затларга) өйләнешүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта**

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрына
балигълык яшенә җитмәгән
______________________________________
(балигълык яшенә җитмәгән баланың фамилиясе, исеме, ата исеме)
ата-анасыннан яисә аларны алыштыра торган затлардан
______________________________________
(балигъ булмаган бала атасының фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Яшим
______________________________________
______________________________________
Тел.
______________________________________
(кесә, өй)
______________________________________
(балигъ булмаган бала әнисенең фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Яшим
______________________________________
______________________________________
Тел.
______________________________________
(кесә, өй)

## Гариза

2009 елның 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 10 статьясындагы 3-4 пункты нигезендә

____________________________________________________________
(кәләшнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы)

___________________________________________________________________________
_

(кияүнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы)

өйләнешүенә ризалык бирәм (бирәбез).

Гаризага теркибез:

(ата-аналарның (аларны алмаштыра торган затларның) шәхесен таныклый торган документларның күчермәләре теркәлә)

| | | |
|---|---|---|
| _______________ | ____________________ | __________________________________________ |
| (дата) | (имза) | (тулы имза) |
| _______________ | _____________________ | __________________________________________ |
| (дата) | (имза) | (тулы имза) |

**Уналты яшенә җитмәгән затка (затларга) өйләнешүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта**

**Уналты яшенә җитмәгән затка (затларга) өйләнешүгә рөхсәт бирү буенча гаризаларны теркәү журналы**

| Т/с | Гариза бирүченең Ф.И.А. | Карауга кабул ителгән документлар | Кабул итү датасы | Кабул ителгән карар (җибәрелгән документның номеры) | Гариза бирүченең документ алу турындагы имзасы | Алу датасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

**Уналты яшенә җитмәгән затка (затларга) өйләнешүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта**

## Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүгә агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары


### Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы

| Вазифа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 294-95-90 | Rafis.Burganov@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 294-96-02 | Alsu.Asadullina@tatar.ru |
| Опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлеге җитәкчесе | 294-95-66 | Venera.Vasileva@tatar.ru |

### Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазифа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге башлыгы | 264-77-20 | Andrey.Vybornov@tatar.ru |

**Уналты яшенә җитмәгән затка (затларга) өйләнешүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта**



**Уналты яшенә җитмәгән затка (затларга) өйләнешүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта**

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрына
кемнән_________________________________
_______________________________________

**Техник хатаны төзәтү турында**
**гариза**

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә ясалган хата турында хәбәр итәм _________________
__________________________________________________________________________
( хатаның төре)
Язылган: _________________________________________________________________
Дөрес мәгълүмат:
__________________________________________________________
Техник хатаны төзәтүегез турында үтенәм.
Түбәндәге документларны терким:

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

Телефон: _________________ E-mail: ________________________________________
Дата ______________ Имза ______________/_________________________________

Хезмәт билгеләре
Гариза килде:
Дата:
Кергән номеры:

гариза кабул иткән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм имзасы